Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«18» ноябрь 2019 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Бикүле торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау (грунттан юл өслеген күтәрү, вак таш сатып алу, ташу, салу, транспорт хезмәтләре);

2) Бикүле авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү;

3) Бикүле авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

Халык җыены рәисе: Р.Х.Садыйков

Бикүле авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Садыйков